РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

2022 елның 18 ноябре Кукмара ш. № 154

Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендәге 152 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы җирле үзидарә органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

consultantplus://offline/ref=779BEAA411990911477F636A0F32AB7F467037CB79A19F4D12BEA6468303DE70F8X8W3KМуниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы , «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына, депутатларга, үз вазыйфаларын даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 17 декабрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендәге 152 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы җирле үзидарә органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), Кукмара муниципаль районы Советының 2020 елның 30 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 04 июнендәге 67 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктының беренче абзацында «11 498» саннарын «11 958» саннары белән алыштырырга;

е) Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫНЫҢ, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫНЫҢ, КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнар белән) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 31660 |
| Башлык урынбасары | 28494 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 28494 |

в) түбәндәге эчтәлекле $8^{-2}$ пунктын өстәргә:

«$8^{2}$. Татарстан Республикасының мактаулы исеме булган муниципаль хезмәткәркә хезмәт окладының 20 проценты күләмендә айлык өстәмә түләнә.»

г) Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең билгән муниципаль вазыйфасына карап, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи окладына калдыксыз бүленә торган күләмдә 12688 сум күләмендә вазыйфаи окладлар билгеләнә.»;

д) Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫНЫҢ, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫНЫҢ, КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнар белән) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 33592 |
| Башлык урынбасары | 30233 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 30233 |

е) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль хезмәткәркә вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләүләр түләнә, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле муниципаль хезмәткәрне элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую очрагыннан тыш, бу очракта акчалата түләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакын элек ул биләгән вазыйфалары буенча акчалата хезмәт хакы күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла».

ж) 3 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 18 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган әлеге карарның 1 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларыннан тыш, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев